Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Иске Суркино авыл җирлегенең
Яңа Суркино авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы карары

5 июнь 2023 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2023 елның 03 июнендә 15 сәгать 30 минутта, 2023 елның 03 июнендә 16 сәгать 30 минутта узган гражданнарның этаплы җыен нәтиҗәләре нигезендә түбәндәге «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Суркино авыл җирлегенең Яңа Суркино авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 28 ноябрендәге 6 номерлы гражданнар җыены карары мәсьәләсенә «гражданнарның үзара салым салу чараларының калдыгы 1 099 225 сум 40 тиен» дигән сүзләрне «гражданнарның үзара салым салу чараларының калдыгы 253 350 сум 81 тиен» дигән сүзләр белән алыштырып үзгәрешләр кертергә ризамы?» соравы буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 180 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 98 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында катнашучыларның 98 «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде; катнашучыларның 0 КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Суркино авыл җирлегенең Яңа Суркино авылында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - чынбарлыкка туры килә.

2. «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Суркино авыл җирлегенең Яңа Суркино авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 28 ноябрендәге 6 номерлы гражданнар җыены карары мәсьәләсенә «гражданнарның үзара салым салу чараларының калдыгы 1 099 225 сум 40 тиен» дигән сүзләрне «гражданнарның үзара салым салу чараларының калдыгы 253 350 сум 81 тиен» дигән сүзләр белән алыштырып үзгәрешләр кертергә ризамы?» турындагы мәсьәлә буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Яңа Суркино авылы, Үзәк урамы, 12А йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Суркино авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Иске Суркино авыл җирлеге башлыгы Н.В. Леонтьев